ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Югары белем бирү мәгариф оешмаларының спорт-савыктыру лагерьларын реконструкцияләү турында Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры В.Н. Фальковка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында

---

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Югары белем бирү мәгариф оешмаларының спорт-савыктыру лагерьларын реконструкцияләү турында Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры В.Н. Фальковка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен (кушымта итеп бирелә) кабул итәргә.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры В.Н. Фальковка җибәрергә.
3. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге мөрәҗәгатен хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БУЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2148-VI ДС

**Югары белем бирү мәгариф оешмаларының спорт-савыктыру лагерьларын реконструкцияләү турында Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министры В.Н. Фальковка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы**

# МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле Валерий Николаевич!

Илебезнең югары белем бирү системасында студент яшьләрне тәрбияләү һәм социальләштерү мәсьәләләренә, шул исәптән социаль инфраструктурадан да файдалану ярдәмендә, һәрвакыт зур әһәмият бирелде. Югары квалификацияле кадрларны әзерләү бурычларын үтәү йөзеннән югары белем бирү мәгариф оешмаларының спорт-савыктыру лагерьлары (алга таба – студент лагерьлары) белем бирү, савыктыру һәм тәрбияләү эшчәнлегендә мөһим роль уйный. Һичшиксез, студент лагерьлары шулай ук Россия Федерациясе регионнары территорияләрендә социаль әһәмияткә ия объектлар исемлегенә керә, яшьләрнең шәхси һәм коллектив үсешенә ярдәм итә.

Ел саен җәйге ял һәм савыктыру программасы якынча 30 процент белем алучыны, нигездә беренче уку елы студентларын, колачлап ала. Лагерьлар базаларында белем алучыларның сәламәт яшәү рәвешен булдыруга, экологик белем бирүгә бәйле уку-укыту программаларының аерым модульләре, аерым төр уку-укыту практикалары гамәлгә ашырыла, хәрби әзерлек һәм спорт әзерлеге буенча сборлар уздырыла.

Студент лагере, яшьләрне социальләштерү мәйданчыгы буларак, граждан-патриотик тәрбия мәсьәләләрен хәл итүдә гаять әһәмиятле роль уйный. Лагерьда тәрбия эше планы традицион рәвештә массакүләм мәдәни чараларга, массакүләм физик культура, спорт һәм үстерү чараларына, шулай ук уку-укыту программаларына бай була. Студент лагерьларының күбесендә ел саен беренче курста белем алучыларның актив мәктәпләре, спартакиадалар, фәнни, экологик юнәлешләр, волонтерлык юнәлешләре буенча профильле сменалар үткәрелә. Моннан тыш, студент яшьләр лагерьда булган вакытта якындагы торак пунктларда яшәүче ветераннарга һәм мәктәп укучыларына шефлык ярдәме күрсәтә.

Мәсәлән, Татарстан Республикасында «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Шеланга», «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Икар», «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Кордон» һәм башка студент лагерьларында ялны оештыруның бай тәҗрибәсе тупланды.

Академик төркемнәр кураторлары, белем алучылар үзләре һәм университетларны тәмамлаучылар, яшьләрне иҗади үстерү урыны буларак, студент лагерьларын югары бәялиләр.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында югары белем бирү мәгариф оешмаларының студент лагерьлары уртача 3 – 7 га мәйдандагы территорияләрдән гыйбарәт, алардагы корылмалар нигездә 1950 – 1970 елларда салынган һәм аларның 40тан алып 80 процентка кадәр өлеше тузган хәлдә. Агач йокы корпуслары эксплуатацияләү дәверендә (50 елдан артык) бик нык тузган. Йортларга агымдагы ремонт ясау яшәүнең санитария-көнкүреш шартларын яхшырту мөмкинлеген бирми. Булган биналарда инженерлык челтәрләрен реконструкцияләү, янгын сигнализациясен кую, гамәлдәге җиһазны алмаштыру кирәк. Моннан тыш, тышкы инженерлык челтәрләренә капиталь ремонт ясау һәм территорияне төзекләндерү таләп ителә. Югарыда күрсәтелгән эшләрне башкармый торып, студент лагерьларын алга таба да эксплуатацияләү мөмкин түгел.

Бүгенге көндә студент лагерьларының эшкә яраклылыгын торгызу, аларда яшәү шартларын яхшырту, аларның иминлеген тәэмин итү, аларны эксплуатацияләү характеристикаларын камилләштерү, аларның конкурентлык сәләтен арттыру өчен ел буе эшли торган уңайлы корпуслар төзү һәм территорияләрне реконструкцияләү зарур. Бер югары белем бирү мәгариф оешмасы өчен эшләр күләменең бәясе уртача 150 млн сум һәм аннан да артыкны тәшкил итәргә мөмкин, бу проблеманы зур күләмдәге акчалар кертмичә генә мөстәкыйль хәл итеп булмаячак. Әлеге мәсьәлә илебезнең күпчелек регионнары өчен актуаль булып тора.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, студент лагерьларын саклауның һәм үстерүнең югары социаль әһәмиятен игътибарга алып, Сездән, хөрмәтле Валерий Николаевич, Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгы тарафыннан аның буйсынуындагы югары белем бирү мәгариф оешмаларының студент лагерьларын федераль бюджет акчалары исәбеннән реконструкцияләү буенча федераль максатчан программаны эшләү мөмкинлеген карауны үтенәбез.

Мондый программаны гамәлгә ашыру киләчәктә студент лагерьларын яшьләрне ел буе яшәтә, савыктыра һәм тәрбияли торган уникаль комплекслы мәйданчыклар итү мөмкинлеген бирәчәк.